ГЛАВА
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2019 с. Сарсак-Омга № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Сарсак-Умга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07. 2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Сарсак-Омга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 9 декабрендә 14 сәг 00 минутта Сарсак-Умга авылы мәдәният йорты бинасында Сарсак-Умга авылында К.Маркс урамы буенча 1-58; Ворошилов урамы буенча 1-17; Береговая урамы буенча 1-18нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
2. 2019 елның 9 декабрендә 16 сәг 00 минутта Сарсак-Умга авылы мәдәният йорты бинасында Сарсак-Умга авылында К.Маркс урамы буенча 59-76; Ленин урамы буенча 1-41; Логовая урамы буенча 1-9, Красноармейская урамы буенча 1-8, Молодежная урамы буенча 1-13, Киров урамы буенча 1-10нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
3. Гражданнар җыены этапларын уздыру һәм оештыру Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә итеп расларга:

« I төркем инвалидларыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган, 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндә санап кителгән эшләрне башкаруга тоту белән килешәсезме?
- Сарсак-Умга авылының Береговая һәм Логовая урамнарына илтүче тыкрыкларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу, җир катламы планировкасы һәм янгын пирсы төзү өчен вак таш балласты җәю;
- Сарсак-Умга авылы зиратын койма белән әйләндереп алу;
- авыл җирлеге чикләрендә кар чистарту;
- Ленин урамы буенча сууткәргеч өчен кое һәм кран урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча, шулай ук Сарсак-Умга авыл җирлегенең башка мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этаплары үткәрелергә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Т.С. НИКОЛАЕВА